| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 июнь 2021 ел № 57

**Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү Нигезләмәсен һәм Тәртибен раслау турында**

Мәгариф оешмалары җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итү, мәгариф оешмаларында нәтиҗәле, алдынгы һәм инновацион менеджментны пропагандалау һәм мәгариф оешмалары җитәкчеләренең укыту-административ процессын оештыру эшчәнлеген ачыклау һәм камилләштерү максатыннан, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Расларга:

1.1. 1 нче кушымта нигезендә Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү турында Нигезләмәне расларга.

1.2. 2 нче кушымта нигезендә Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү Тәртибен расларга.

2. Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бу максатларга җирле бюджетта каралган ассигнование чикләрендә финанслауны гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач район Советы рәисе,
Балтач муниципаль районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның 7 июнендәге
57 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» гранты алуга конкурс (алга таба - Конкурс) оештыруны һәм үткәрүне билгели.

1.2. Конкурс мәгариф оешмасы җитәкчесенең өзлексез һөнәри һәм шәхси үсешен үстерүгә идарә практикасының иң яхшы үрнәкләрен трансляцияләүгә һәм инновацион идеяләрне һәм казанышларны пропагандалауга юнәлтелгән.

1.3. Конкурсны әзерләү, оештыру һәм үткәрү белән «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУсе шөгыльләнә.

1.4. Конкурс белән җитәкчелек итү өчен Комиссия төзелә (алга таба - Комиссия).

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс мәгариф оешмалары җитәкчеләренең һөнәри компетенцияләрен үстерү хисабына аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итү, шулай ук мәгариф оешмаларында нәтиҗәле, алдынгы һәм инновацион менеджментны пропагандалау максатларында үткәрелә.

2.2. Конкурсның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- мәгариф оешмалары җитәкчеләренең укыту-административ процессын оештыру эшчәнлеген ачыклау һәм камилләштерү;
- җитәкчеләрдә идарә итү инициативасын, тапкырлык, стандарт булмаган фикерләүне үстерүне стимуллаштыру;
- инновацион проектларны, методикаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, инновацион технологияләрне өйрәнүгә һәм аларны мәгариф оешмалары эшенә кертүгә ихтыяҗ булдыру;
- уңышка ирешкән җитәкчеләрне ачыклау һәм аларның Балтач муниципаль районы мәгариф системасы үсешенә керткән шәхси өлешләрен халык алдында таныту;
- Балтач муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренең уңай һәм һөнәри имиджын формалаштыру;
- Балтач муниципаль районы мәгариф оешмаларының иң яхшы җитәкчеләрен бүләкләү һәм аларга ярдәм күрсәтү.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста Балтач муниципаль районының «Директор, Мөдир» вазыйфасында 3 елдан да ким булмаган өзлексез эш стажы булган (гариза биргән вакытка) мәгариф оешмалары җитәкчеләре катнаша ала. Җиңүче әлеге конкурста киләсе өч ел дәвамында катнаша алмый.

## 4. Конкурсны үткәрү этаплары

4.1. Конкурсның түбәндәге этаплары билгеләнә:

I этап - читтән торып катнашу этабы;

II этап – килеп катнашу этабы.

4.2. Конкурс этапларын уздыруны оештыру-методик тәэмин итү өчен түбәндәгеләр билгеләнә: Комиссия; Конкурс этапларын үткәрү тәртибе, вакытлары һәм процедурасы; Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү тәртибе раслана.

4.3. Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабында җиңүчеләр икенче килеп катнашу этабында катнаша.

4.4. Конкурсны үткәрү вакыты, бирелә торган материаллар, конкурс сынаулары һәм бәяләү критерийлары турында тулырак мәгълүмат конкурсны үткәрү тәртибендә бирелә.

## 5. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм Комиссия әгъзаларыннан тора. Гомуми состав 13 кешедән артмый.

5.2. Комиссия составы Балтач муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

5.3. Конкурс комиссиясе:

- Конкурска әзерлек һәм аны уздыру турында мәгълүматны катнашучыларга җиткерүне тәэмин итә;
- Конкурс үткәрү Тәртибенә һәм конкурс биремнәрен бәяләү критерийларына үзгәрешләр кертү өчен тәкъдимнәр әзерли;
- Конкурста катнашу өчен кандидатларның материалларын кабул итә;
- Конкурс документларын алып бара;
- бәхәсле мәсьәләләрне хәл итә;
- Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү Тәртибе нигезендә конкурс үткәрә;
- массакүләм мәгълүмат чараларына Конкурс үткәрү турында хәбәр итә;
- Конкурста катнашучыларны бүләкләү тантанасын оештыра.

5.4. Комиссия әгъзалары анализ үткәрәләр, бәяләр куялар, конкурс сынаулары нәтиҗәләре буенча карарлар чыгаралар. Һәр конкурс сынавы буенча Комиссия әгъзалары уздыру тәртибендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәяләү ведомостьларын тутыралар.

5.5. Комиссия әгъзалары үз эшләрендә Конкурс үткәрү тәртибендә күрсәтелгән Конкурс турындагы Нигезләмә белән расланган бәяләү критерийларын кулланалар.

5.6. Комиссия әгъзалары Конкурста җиңүчене билгелиләр.

5.7. Әгәр аның өчен исемлек составының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, Комиссия карары кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе өстәмә тавышка ия. Карар комиссия рәисе имзасы белән, ә ул булмаганда – урынбасар һәм секретарь имзасы белән рәсмиләштерелә.

## 6. Конкурс җиңүчеләрен билгеләү

6.1. Комиссия конкурс сынауларын башкаруны Конкурсны үткәрү тәртибе белән расланган критерийлар нигезендә балларда бәяли.

6.2. Конкурсның конкрет катнашучысына куелган баллар санын санау алгоритмы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

6.2.1. Читтән торып үткәрелгән этап нәтиҗәләре буенча катнашучыга һәр Комиссия әгъзасыннан алынган һәр конкурс сынавы өчен уртача арифметик балл суммасыннан торган бәя куела.

6.2.2. Конкурсның килеп катнашу этабы йомгаклары буенча катнашучыларга Комиссия әгъзаларыннан алынган һәр конкурс сынавы өчен уртача арифметик баллны тәшкил иткән бәя куела.

6.2.3. Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабы нәтиҗәләре суммасы буенча иң күп балл җыйган 10 катнашучы, конкурс лауреатлары дип игълан ителә, алар килеп катнашу этабында катнаша. Лауреатларның баллары юк ителә.

6.2.4. Конкурсның килеп катнашу этабының һәр сынавы биремнәрендә катнашучыга Комиссиядан алынган балларның арифметик күләмен тәшкил иткән бәя бирелә.

6.3.6. Конкурсның килеп катнашу этабында иң күп балл җыйган 10 лауреат арасыннан өч катнашучы конкурс җиңүчеләре дип игълан ителә: 1 гомуми белем бирү учреждениесе директоры, 1 башлангыч мәктәп-балалар бакчасы директоры, 1 балалар бакчасы мөдире.

## 7. Конкурска йомгак ясау

7.1. Конкурсның килеп катнашу этабының барлык катнашучылары да конкурста катнашучы сертификатлары белән бүләкләнә.

7.2. Җиңүчеләр түбәндәге күләмдәге акчалата бүләкләр белән бүләкләнә: гомуми белем бирү учреждениесе директоры - 40 000,00 сум, башлангыч

мәктәп-балалар бакчасы директоры - 30 000,00 сум, балалар бакчасы мөдире - 30 000,00 сум.

## 8. Бәхәсле мәсьәләләрне хәл итү

8.1. Конкурста катнашучылар, конкурс сынаулары нәтиҗәләрен игълан иткән мизгелдән соң бер тәүлек эчендә апелляция биреп, һәр тур нәтиҗәләре буенча Комиссия карарын кире кагу хокукына ия.

8.2. Апелляция моның өчен кирәкле белгечләрне җәлеп итеп һәм кирәкле документларны карап тикшерелә.

8.3. Карар апелляция биргән Конкурста катнашучыга һәм жюрига апелляция биргән көннән алып 14 календарь көн өчендә җиткерелә.

Балтач район Советының
2021 елның 7 июнендәге
57 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү Тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибе Балтач муниципаль районы башлыгының «Мәгариф оешмасының иң яхшы җитәкчесе» грантын алуга конкурс үткәрү турында нигезләмә нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Конкурсны уздыру вакытларын, Конкурста катнашу өчен тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеген, конкурс сынаулары структурасын, аларны үткәрү форматын һәм бәяләү критерийларын билгели.

1.3. Конкурсны оештыруны, әзерләүне һәм үткәрүне «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тәэмин итә.

1.4. Конкурсның этаплары:

- беренче (читтән торып катнашу) - агымдагы елның августы;
- икенче (килеп катнашу) - агымдагы елның сентябре.

**2. Конкурста катнашу өчен документлар һәм материаллар тапшыру**

2.1. Конкурста катнашу өчен Конкурс комиссиясенә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- катнашучыны тәкъдим итү
- Конкурста катнашучының мәгълүмати картасы (Тәртипкә кушымта);
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (Тәртипкә кушымта);

2.2. Читтән торып катнашу туры материаллары Конкурс комиссиясенә агымдагы елның 15 августына кадәр электрон рәвештә бирелә.

2.3. Конкурсның читтән торып катнашу этабы нәтиҗәләре агымдагы елның 30 августына Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ сайтында тәкъдим ителәчәк.

2.4. Катнашучылардан вакытларын һәм аларны рәсмиләштерү таләпләрен бозып кергән материаллар карап тикшерелергә тиеш түгел.

2.5. Конкурска тәкъдим ителгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

2.6. Конкурста катнашу өчен документлар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422250, Балтач ш.т.п., Ленин урамы, 63 нче йорт, 35 нче кабинет, «Иң яхшы мәгариф оешмасы җитәкчесе» тамгасы белән.

## 3. Читтән торып катнашу этабының конкурс чаралары

3.1. Читтән торып катнашу этабында конкурсантның бирелгән материалларына экспертиза үткәрелә.

3.2. «Җитәкче-аналитик» читтән торып катнашу туры өч конкурс сынавыннан тора:

- «Мин-директор», «Мин-мөдир»;
- «Директорның шәхси сәхифәсе», «Мөдирнең шәхси сәхифәсе".

3.2.1. «Мин - директор», «Мин - мөдир» конкурс сынавы.

Максат: Үзеңнең идарә эшчәнлегеңә, үз оешмаңның проблемаларына заманча шартларда, оешма контекстын исәпкә алып, проблемаларны хәл итүнең иң нәтиҗәле юлларын сайлап алуга рефлекссияне һәм анализны гамәлгә ашыру осталыгын ачу.

Конкурс сынавы форматы: эссе (3 биткә кадәр А4 форматындагы басма текст):

шрифты - Times New Roman,
- юл арасындагы ара - 1,5,
- хәреф арасындагы ара - гадәти,
- шрифт төсе кара,
- шрифт размеры - кегль 12,
- кырларның размеры: уң як - 10 мм, өске һәм аскы яклар – 20 мм, сул як – 30 мм).

Эссе темасы « Белем сыйфаты: ачык мөмкинлекләр».

Конкурс сынавын үтәүне бәяләү 5 критерий буенча башкарыла. Конкрет күрсәткечкә туры килү сыйфат ягыннан бәяләнә һәм таблица нигезендә балларга күчерелә.

| Критерий | Катнашучының эше критерийга туры килә | Балл |
|---|---|---|
| Мәктәп (бакча) эшчәнлеге контексты анализлана торган проблеманы исәпкә алып бирелде | Әйе | 3 |
| | Мөгаен әйе | 2 |
| | Мөгаен юк | 1 |
| | Юк | 0 |
| Әлеге тема кысаларында җитәкче эшчәнлегендә проблемалар һәм күрсәтелгән каршылыкларны хәл итәргә мөмкинлек бирүче идарә итү гамәлләре тасвирланды | Әйе | 3 |
| | Мөгаен әйе | 2 |
| | Мөгаен юк | 1 |
| | Юк | 0 |
| Кабул ителгән идарә карарлары, аларның | Әйе | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләре тасвирланды һәм алынган нәтиҗәләргә тәнкыйти анализ бирелде | Мөгаен әйе | 2 |
| | Мөгаен юк | 1 |
| | Юк | 0 |
| Авторның шәхси позициясе, үз идарә эшчәнлегенең төрле аспектлары, фикерләү тәнкыйте бар | Әйе | 3 |
| | Мөгаен әйе | 2 |
| | Мөгаен юк | 1 |
| | Юк | 0 |
| Тәкъдим ителгән материал оригиналь, артык гыйльми булмаган, тере һәм образлы профессиональ телдә бәян ителгән | Әйе | 3 |
| | Мөгаен әйе | 2 |
| | Мөгаен юк | 1 |
| | Юк | 0 |
| Мөмкин булган максималь бал | | 15 |

3.2.2. «Директорның шәхси сәхифәсе», «Мөдирнең шәхси сәхифәсе» конкурс сынавы.

Максат: педагогның һөнәри эшчәнлеге сыйфатын күтәрү ресурсы буларак мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллануны күрсәтү.

Формат: инновацион тәҗрибәне чагылдыручы, Интернет челтәрендә белем бирү мәгълүматын күзаллау культурасын күрсәтә торган белем бирү, мәгълүмат, методик һәм (яисә) башка эшләнмәләре булган мәгариф оешмасы сайтында (сайт, блог, социаль челтәрләрдә сәхифәләр һ.б.) шәхси битне күрсәтү.

Конкурс сынавын үтәүне бәяләү 5 критерий буенча башкарыла, аларның һәркайсы 3 балл белән бәяләнә һәм тигез әһәмияткә ия. Максималь гомуми балл - 15.

Бәяләү критерийлары:

- тапшырылган материалларның саны, сыйфаты һәм тематик оештырылуы;
- тапшырылган материалларның белем бирү һәм социаль мәдәни кыйммәте;
- тапшырылган материалларның актуальлеге;
- кире элемтәнең нәтиҗәлелеге;
- дизайнның оригинальлеге һәм тәңгәллеге (адекватлыгы).

«Директор - аналитик», «Мөдир – аналитик» конкурсының читтән торып катнашу этабы нәтиҗәләре буенча конкурста 12 кешегә кадәр катнашучылар сайлап алына (һәр категориядән 4әр катнашучы, алар Конкурсның килеп катнашу этабына рөхсәт ителә).

3.2.3. «Директорның һәм мөдирнең районның (җирлекнең) иҗтимагый тормышында катнашуы» конкурс сынавы.

Максат: җитәкченең район (җирлек) чараларында эшчәнлеген бәяләү.

Критерийлар өч баллы шкала буенча бәяләнә.

| Критерий | Мәгълүмат бирү өчен җаваплы зат | Бәяләү тәртибе |
|---|---|---|
| Ел дәвамында мәгариф оешмалары территорияләрен төзекләндерүне тәэмин итү | Административ комиссия секретаре һәм җирлек башлыклары | Z = (Y *100)/ X<br>Биредә X - затларның гомуми саны (хезмәткәрләр + мәктәп укучылары),<br>Y - катнашучы затлар саны,<br>Z - процент нисбәте,<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Спорт чараларында катнашу дәрәҗәсе (мәктәпара) | Яшьләр бүлеге | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - чараларның гомуми саны,<br>Y - оешмалар катнашкан чаралар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Мәдәни чараларда катнашу дәрәҗәсе | Мәдәният бүлеге | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - затларның гомуми саны (хезмәткәрләр + мәктәп укучылары),<br>Y - катнашучы затлар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Шикаятьләр һәм кисәтүләр | Балтач район башкарма комитеты | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - шикаятьләрнең гомуми саны,<br>Y - җитәкчегә карата шикаятьләр саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Җинаятьчелек дәрәҗәсе (балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекләр (ПДН), балигъ булмаганнар эшләре буенча | КДН (ЭЭМ) | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - балаларның гомуми саны,<br>Y - исәптә торучы балалар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 0 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 2 балл<br>Әгәр Z 0дән 3кә кадәр булса - 3 балл |

| | | |
|---|---|---|
| комиссия (КДН) исәбендә торучылар саны) | | |
| Балаларның җәйге ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру | Эшкә урнаштыру буенча «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (ЦЗН ДКУ) | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - балаларның гомуми саны,<br>Y - эшкә урнаштырылган балалар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| | Ял итү буенча МКУ | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - балаларның гомуми саны,<br>Y - ял итүче балалар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Җирлек территориясендә мәгариф оешмаларының иҗтимагый тормышында катнашу | Авыл (шәһәр) җирлеге | Z = (Y * 100)/ X<br>Биредә X - чараларның гомуми саны,<br>Y - катнашучы хезмәткәрләр һәм балалар саны,<br>Z - процент нисбәте<br>Әгәр Z 70тән 100гә кадәр булса - 3 балл<br>Әгәр Z 30дан 70кә кадәр - 2 балл<br>Әгәр Z 1дән 30га кадәр булса - 1 балл<br>Әгәр Z 0дән 1гә кадәр булса - 0 балл |
| Бюджет һәм бюджеттан тыш акчаларның нәтиҗәле тотылуын тәэмин итү | Финанс-бюджет палатасы | ФБП тикшерү нәтиҗәләре буенча өч баллы шкала буенча бәяләнә |

**4. Килеп катнашу этабының конкурс чаралары**

4.1. Конкурсның килеп катнашу этабы бер турда үткәрелә:
4.2. Килеп катнашу этабының конкурс сынаулары:
4.2.2. «Халык алдында чыгыш» Конкурс сынавы.

Максат: идарә итүнең тактик бурычларын хәл итә белүне, идарә теориясенең практикага нисбәтен, үз идарә эшчәнлегең анализлауга, аңлауга һәм күзаллауга осталыгын күрсәтү.

Конкурс сынавының форматы: халык алдында чыгыш.

Конкурс сынавын үтәүне бәяләү күрсәткечләр җыелмасыннан торган 8 критерий буенча гамәлгә ашырыла. Һәр критерий буенча максималь 5 балл куела. Конкурс сынавы өчен максималь гомуми балл - 40 балл. Критерийлар һәм күрсәткечләр эзлеклелеге принципиаль әһәмияткә ия түгел.

Сынауны бәяләү критерийлары:

- мәгариф оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган белем бирү стратегияләрен гамәлгә ашыру белән нәтиҗәле идарә итү аспектлары турында фикер алышу;

- укытучыларның һәм хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм лидерлык сыйфатларын камилләштерү буенча эшчәнлекне теркәү;

- мәгариф оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, шул исәптән укучыларның федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә торган казанышларын бәяләү аспектлары турында фикер алышу;

- укучыларның мөмкинлекләренә, мәгариф оешмасы потенциалына һәм социум ихтыяҗларына туры килә торган педагогик технологияләрне сайлап алу аспектлары турында фикер алышу;

- әйтелгән тәкъдимнәрнең мәгариф оешмалары эшчәнлегенең норматив-хокукый нигезләре белән каршылыксызлыгы;

- халык алдында чыгышның культурасы, сөйләмнең логикага нигезләнгәнлеге һәм образлылыгы, харизмалылык.

4.3. Барлык конкурс сынауларының эзлеклелеге жирәбә белән билгеләнә.

4.4. Конкурс лауреатлары арасыннан конкурсның килеп катнашу этабы сынаулары өчен җыелган баллар суммасы буенча конкурсның 3 җиңүчесе игълан ителә.